ГОСУДАРСТВЕННЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2020 Казан ш. № 385-183/кс-2020

«Нурлат торак-коммуналь хуҗалык күптармаклы җитештерү предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2021 елга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Нурлат торак-коммуналь хуҗалык күптармаклы җитештерү предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «Нурлат торак-коммуналь хуҗалык күптармаклы җитештерү предприятиесе» МУП) тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Нурлат торак-коммуналь хуҗалык күптармаклы җитештерү предприятиесе» МУП Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу

стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
09.12.2020 № 385-183/кс-2020 карарына
кушымта

Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Нурлат торак-коммуналь хуҗалык күптармаклы җитештерү предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2021 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (ике компонентлы) | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м | | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал | |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Нурлат торак-коммуналь хуҗалык күптармаклы җитештерү предприятиесе» МУП** | 34,40 | 35,40 | - | - |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.
<**> Җылылык энергиясенә компонент яклар килешүе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую нигезләренең 5(5) пункты нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге